


Татар теле халыкара олимпиадасы 2012 елда ТР Президенты Ростәм Миннеханов хәер-фатихасында башланган, быел 22-25 апрельдә VII тапкыр vтте. Татар теленнән халыкара олимпиаданын йомгаклау олешендә Татарстан мәктәпләреннән - 232, 15 чит илдән - 50, Россиянен 26 тобәгеннән һәм якшәмбе мәктәпләреннән 191 кеше катнашты. Татарстан һәм илнен торле тобәкләреннән 40 студент коч сынашты. Шул исәптән, Мордовиянен торле районнарыннан жиде укучы һәм бер студент катнаштылар: Ләмберә районы Татар Тавла мәктәбе 9 сыйныф укучылары Эльвина Алукаева белән Карина Муртазина, Черемиш  мәктәбе 8 сыйныф укучысы Тимерлан Карабанов, Рузаевка районы Татар Пешлә урта мәктәбе 8 сыйныф укучысы Диана Биксаляева белән 10 сыйныф укучысы Камила Чугунова, Ромоданово районы Белозерье мәктәбе 9 сыйныф укучысы Мәрьям Аберхаева, Кадошкино районы Латышовка мәктәбе 10 сыйныф укучысы Марат Бадамшин, М.Е.Евсевьев исемендәге Мордовия педагогия институты татар теле бvлеге 3нче курс студенты Карина Овчинникова.       Олимпиада читтән торып һәм кондезге этаплардан торды. Анда 8-11 сыйныф укучылары, шулай ук студентлар катнашты. Укучыларны алып килгән педагоглар белән семинар vткәрделәр. Ләмберә районы югары квалификацияле татар теле укытучылары Черемиш мәктәбеннән Фазия Фәрит кызы Боярова белән Татар Тавласы мәктәбеннән Альфия Фатих кызы Муртазина катнашып, сертификатлар алып кайттылар.

Рузаевка районы Шәриф Камал исемендәге Татар Пешлә урта мәктәбендә татар телен ойрәнvгә, милли узан булдыруга зур коч куялар. Милли эчтәлекле кvп кенә чаралар vткәрәләр. Татар теле һәм әдәбияты олимпиадаларында район, республика, регионара һәм халыкарасында жинvчеләрне тәрбиялиләр. Шулай VII татар теле  халыкара олимпиадасында Мордовиядә мактаулы татар теле укытучысы Сания Спартак кызы Саляеванын  укучысы Камила Чугунова призерлыкны яулап кайтты.

Призер Камила Чугунова әнгәмә-сендә: «Шушы жинvемә чиксез шатмын. Чит регион, чит ил кешеләре белән таныштык. Кvп музей һәм театрларда булдык, «Мин татарча сойләшәм» акциясен, проект эшләр яклауны кvрдек, Туган тел форумында катнаштык. Тагын бер елдан да ярышта катнашасы килә. Биремнәргә килгәндә, житдирәк

әзерләнергә кирәк икән, дигән нәтижәгә килдем, гәрчә Сания Спартаковна белән дәрестән сон калып шогыльләнсәк тә. Татарстан тарихы авыррак булды, бездә ойрәнелмәгәч, без аны белмибез. Тагы, мишәр диалекты булгач, телнен грамматикасы да кыенрак булды», - диде.
Гран-прины япон егете Чихиро Тагучи, Татарстаннын Чирмешән районыннан Лилия Гатина һәм



Башкортстаннан Тимур Суфиянов яулады. 60 кеше олимпиаданын призерлары исемлегендә. 20 кеше жинvчеләр итеп билгеләнде. Татар теленнән халыкара олимпиада жинvчеләрен Татарстаннын Дәvләт Советы Рәисе Фәрит Мохәммәтшин бvләкләде. Ул чыгышында: «Мин – татар, әти-әнием – татар, башкалардан ким тvгел бит, дип туган телемне ойрәнергә булдым. Урыс авылында бердәнбер татар гаиләсе идек. Мине «татарин» дип vртиләр иде. Колгән очен гарьләнә идем. Эштән кайткач, козге янына басып, татарча газеталар укыдым. Анламаган сvзләрнен мәгънәсен хезмәттәшләремнән сорадым. Урысча «стена» сvзе бар, ә татарча ничек? «Запас» дигән сvзне белми идем, анысын да ойрәндем. Татарча ойрәнергә Туфан һәм Роберт Миннуллиннар, Разил Вәлиев һәм башка шәхесләр булышты. Туган телендә, әби-бабайлар телендә сойләшсән, vзенне ботенләй икенче торле хис итәсен икән, – диде Фәрит Мохәммәтшин, кvнелен ачып. – Мин сезнен белән горурланып утырдым бvген. Телне саклап калган, кызыксына торган татар балаларын жиденче тапкыр жыеп, дуслаштырып, сезгә кvрсәтә алдык – шуна соенәм. Доньяда татар телендә сойләшvчеләр тагын да артыр дип ышанам».
Татарстан Премьер-министры урынбасары, Милли шура рәисе Васил Шәйхразиев та vз теләкләрен житкерде: «Сезне мәркәзебездә жыю – дорес карар. Телсез кеше була ала, ләкин милләт телсез була алмый. Барыбыз да татар булып туганбыз, vзебезнен әти-әни телен, Тукай телен белергә тиеш. Әти-әниен, әби-бабан татарча сойләшкән очен генә тvгел, балаларын, оныкларын сойләшкән очен горурлан! Сойләшик, жырлыйк, фикер йортик! Мәхәббәтне дә ана телендә анлатыгыз! – диде ул, яшьләргә морәжәгать итеп. – Татар теле беркайчан да кухня һәм урам теле генә булмады. Ул – дәvләт теле. Бvген vзегезгә лаек булган «5»лене алдыгыз, аны югалта кvрмәгез! Бер-берегез белән дус булып, аралашып яшәгез!»
ТР Премьер-министры урынбасары – мәгариф һәм фән министры Рафис Борһанов чыгышында: «Ана теле – кешенен тормыш чыганагы. Туган тел – буыннардан буыннарга тапшырыла торган рухи байлык. Милләтебез очен тырышып хезмәт итегез», - дип морәжәгать итте министр яшьләргә. Чыгышыннан сон, ул торле тобәкләрдән атказанган татар теле һәм әдәбияты укытучыларын бvләкләде.

Тантаналы чарада, шулай ук, «Ана теле» онлайн мәктәбенен рус телле укучылары арасында ин актив кулланучылары билгеләп vтелде. Жинvчеләрне ТР язучылар Берлеге рәисе Данил Салихов та котлады. Ул чыгышында бик кvп шәхесләрнен татар теле аша танылуларын билгеләп vтте.
Олимпиаданын программасы бик матур һәм тыгыз булды. Казан шәһәре музейларында (Г.Тукай, К.Насыйри, Милли музей) булдык, К.Тинчурин Татар дәvләт, Г.Камал Татар дәvләт академия, Татар дәvләт курчак театрларында спектакльләр карадык. Укучыларыбыз бик канәгать, кочле эмоцияләр алып кайттык.

**Альфия Муртазина,**
*Лэмберэ районы Татар Тавла мэктэбе татар теле укытучысы*